**Әти-әниләр игътибарына!**

Хөрмәтле әти-әниләр!

Арбор төп гомуми белем бирү мәктәбендә 2026-2027 нче уку елына

1 нче сыйныфка укучылар кабул итү башланды.

Баласын Арбор төп гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфына укырга бирергә теләгән әти-әниләрне 1 нче апрель көнне мәктәп администрациясе “Ачык ишекләр көне”нә чакыра. Үзегез белән түбәндәге документларны алып килүегезне сорыйбыз:

1. Баланың туу турында таныклыгы (оригинал һәм копия).
2. СНИЛС (оригинал һәм копия).
3. Әти-әнисенең паспорты (оригинал һәм копия).
4. Яшәү урыны турында белешмә (форма 8 – Паспорт өстәленнән алына (Паспортный стол), әлеге белешмәне алу өчен баланың әтисенең яки әнисенең паспорты һәм баланың туу турында таныклыгы белән барырга кирәк.
5. ЕСИА пароле.

Үзегез белән телефоныгыз булу сорала.

Сезне 1 нче апрель көнне сәгать 10.00 түбәндәге адрес буенча көтәбез:

Арбор авылы, Татарстан урамы, 59 нчы йорт

Мәктәп администрациясе